ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАЙРЯКИ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Новая, д.37, с. Байряки-Тамак, 423964

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӘЙРӘКӘ-ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Яңа урамы, 37йорт, Бәйрәкә-Тамак ав., 423964

Тел.:(85593) 5-13-25, факс:5-13-24, e-mail:Btam.Utz@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**
№17 **30.11.2023 ел**

Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башкарма комитетының 2013 елның 16 сентябрендәге «Бәйрәкәтамак авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында»гы 20 санлы карарын үз көчен югалткан дип тану хакында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2007 елның 02 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 25-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Бәйрәкәтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, норматив хокукый актларны Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. 2013 елның 16 сентябрендәге «Бәйрәкәтамак авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында»гы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башкарма комитетының 20 санлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәмТатарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының сайтында, Татарстан Республикасының Бердәм дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башлыгы урынбасары Ф.Г.Локманов